**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авылында узган гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

1 апрель, 2024 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үз идарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үз идарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авыл җирлеге Уставына,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Хутор торак пунктында гражданнарның үз ара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2024 елның 21 мартындагы 5 номерлы карары нигезендә, гражданнар җыенының 2024 елның 1 апрелендәге 4 номерлы йомгаклау беркетмәсен игътибарга алып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Хутор торак пунктында узган гражданнар җыены КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор торак пунктында узган гражданнар җыенының 2023 елның 22 ноябрендәге 5 номерлы карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Хутор авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндез укып белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре, һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үз ара салым кертергә, тупланган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдаланырга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга;
- торак пункт территориясен төзекләндерүгә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Хутор торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында:Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Хутор авылы, Яшьлек урамы, 5 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы урынбасары Моталлапов Н.Н

СОВЕТ
ШУМКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000845
ШУМКОВО
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ